ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.10.2025 ел Баулы шәһәре №155

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулынефть» нефть - газ чыгару идарәсенең Бохараев нефть ятмасында нефть җыю системасын реконструкцияләү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы белән расланган, Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә (җәмәгать фикер алышулары) нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулынефть» нефть - газ чыгару идарәсенең Бохараев нефть ятмасында нефть җыю системасын реконструкцияләү проекты (алга таба-Проект) буенча 2025 елның 17 октябрендә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә: Татарстан Республикасы, Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20 й., каб. №200.

2. Проект буенча гавами тыңлаулар инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Гавами тыңлауларны үткәрү вакытын 2025 елның 3 октябреннән 2025 елның 16 октябренә кадәр билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен 2025 елның 3 октябрендә ачарга:

4.1. Экспозицияне үткәрү вакыты 2025 елның 3 октябреннән 2025 елның 16 октябренә кадәр 14 көн.

4.2. Экспозицияне үткәрү:

- Баулы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://bavly.tatarstan.ru;

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Татар Кандызы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Татар Кандызы авылы, Совет урамы, 166 йорт адресы буенча;

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Яңа Чүте авылы, Мәктәп урамы, 11 йорт.

4.3. Экспозицияне карау режимы: Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Татар Кандызы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Татар Кандызы авылы, Совет урамы, 166 йорт адресы буенча;

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Яңа Чүте авылы, Мәктәп урамы, 11 йорт.

5. Гавами тыңлауларда катнашучылар 2025 елның 3 октябреннән 2025 елның 16 октябренә кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты буенча 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә гавами тыңлауларда каралырга тиешле Проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язма рәвештә иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга: Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20 йорт, 101 нче кабинет адресы буенча;

- bauly.arch@mail.ru электрон почтасы аша.

6. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2 Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих һәм Татар Кандызы авыл җирлекләре Башкарма комитетлары биналарында урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге http://bauly.tatarstan.ru сайтында проект буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итүне бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Салих һәм Татар Кандызы авыл җирлекләре Башкарма комитетлары биналарында 2025 елның 3 октябреннән 2025 елның 16 октябренә кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты буенча 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә, шулай ук «Интернет» челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында http://bauly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
башлыгы И.И. Гозәеров